СОВЕТ КАРАДУВАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КАРАДУГАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«14» апреля 2025 ел. №121

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Карадуган авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымы һәм гражданнарның үзара салымын җыю һәм файдалану тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Балтач районы прокуратурасының гражданнарның үзара салым салу турындагы Нигезләмәгә протестына, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Карадуган авыл җирлеге Уставына нигезләнеп, Балтач муниципаль районы Карадуган авыл җирлеге Советы карар чыгарды:
1. Карадуган авыл җирлеге Советының 11.04.2014 ел, 101 номерлы карары белән расланган " Карадуган авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымы һәм гражданнарның үзара салымын җыю һәм файдалану тәртибе турындагы нигезләмәгә" түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1.2 пунктының 2 абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:

"Гражданнарның үзара салым акчалары дип җирле әһәмияттәге конкрет мәсьәләләрне хәл итү өчен гражданнар тарафыннан башкарыла торган бер тапкыр түләүләр аңлашыла. Гражданнарның үзара салымы тәртибендә түләүләр күләме авыл җирлегендә яшәүчеләрнең барысы өчен дә бердәй күләмдә билгеләнә, аерым категория гражданнардан тыш, аларның саны авыл җирлегендә яшәүчеләрнең гомуми санынnan 30 проценттан артмаска тиеш һәм алар өчен түләүләр күләме киметелергә мөмкин.".

1.2. Нигезләмәнең 2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

"2.1. Гражданнарның әлеге Нигезләмәнең 1.2 пунктының 2 абзацында күрсәтелгән бер тапкыр түләүләрен кертү һәм файдалану мәсьәләләре җирле референдумда, ә 06.10.2003 ел, 131-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне

оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законның 25.1 статьясының 1 өлешенең 4, 4.1 һәм 4.3 пунктларында каралган очракларда гражданнар җыенында хәл ителә.".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы(http://pravo.tatarstan.ru) хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Балтач муниципаль районының (www.baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Карадуган авыл җирлеге башлыгы: Ш.В.Низамиев